| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.01.2017 Казан шәһәре № под-33/17

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме турында

Республиканың гомуми белем бирү оешмалары укытучыларың педагогик эшчәнлектә һөнәри компетенцияләр белән идарә итү дәрәҗәсен күтәрү һәм аларның иҗади потенциалын үстерү, шулай ук иң яхшы педагогик тәҗрибәне тарату, педагогик хезмәт абруен күтәрү максатында б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме турында тәкъдим ителгән Положениене расларга.

2. Грант ярдәмен финанслау Министрлыкның җыелма сметасында каралган акчалар хисабына гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр Э.Н.Фәттахов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
2017 елның 12 гыйнварында
кабул ителгән № под-33/17
боерыгы белән

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме турында

Положение

## 1. Гомуми положениеләр

1.1. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме (алга таба - Грант ярдәме) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының педагогик эшчәнлектә һөнәри компетенцияләрне белү дәрәҗәсен арттыруга һәм аларның иҗади потенциалын үстерүгә алга таба кызыксындыру максатларында гамәлгә куелды. Грант ярдәме 2017 елда гамәлгә ашырыла

Грант ярдәме әлеге положениедә билгеләнгән критерий һәм таләпләргә туры килә торган, Татарстан Республикасы мәгариф системасына караган, түбәндәге : рус теле, татар теле, әдәбияты, чуаш теле, удмурт теле, мари теле, нглиз теле, алман теле, француз теле, математика, информатика, химия, физика, биология, география, тарих, җәмгыять белеме, физик культура, технология, сынлы сәнгать (бөтендөнья сәнгать культурасы), тормыш иминлеге нигезләре фәннәре буенча гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы беренче һәм югары категорияле укытучылар, шулай ук башлангыч сыйныф укытучылары (алга таба - грант алучы) өчен билгеләнгән.

1.2. Беренче квалификация категориясенә ия булган укытучыларга, грант ярдәмен гамәлгә ашыру өчен, ике " Өлкән укытучы» һәм «Укытучы-мастер»номинацияләре кертелә.

Югары квалификация категориясенә ия булган укытучыларга, грант ярдәмен гамәлгә ашыру өчен, " Укытучы – остаз" һәм " Укытучы – эксперт" номинацияләре кертелә.

2017 елда Грант ярдәмен алуга конкурста укытучылар, шул исәптән 2016 елның Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының беренче категорияле укытучыларының һөнәри үсешенә Грант ярдәменең җиңүчеләре, 2016 елда Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәменең «Укытучы - остаз» һәм «Укытучы - эксперт» номинацияләрендә җиңүче укытучылары катнаша ала.

"Өлкән укытучы» номинациясендә грант ярдәме алуга дәгъва кылучы беренче квалификация категориясенә беренче тапкыр ия булырга, 2017 елда грант алучыны һөнәри яктан үстерүгә юнәлдерелгән проектның тасвирламасын тәкъдим итәргә тиеш.

"Укытучы - мастер» номинациясендә грант ярдәме алуга дәгъва кылучы, расланган беренче квалификация категориясенә берничә тапкыр ия булырга, республика олимпиадаларының муниципаль этабында җиңүче укучылары яки соңгы 3 ел дәвамында ул Һөнәри осталык бәйгеләренең муниципаль яки республика этапы җиңүчесе булырга,2017 елда муниципаль районда тормышка ашырырга мөмкин булган һәм укучыларның үсешенә юнәлдерелгән проектның (укытыла торган фән өлкәсендә)тасвирламасын тәкъдим итәргә тиеш.

"Укытучы-остаз» номинациясендә грант ярдәме алуга дәгъва кылучы югары квалификация категориясенә ия булырга тиеш. Укытучы –предметник буларак, дәгъва кылучының соңгы 3 ел эчендә республика олимпиадаларының муниципаль этабында җиңүче укучылары (2 ел рәттән җиңүче булган бер укучыдан да ким булмаган яки бер ел эчендә - ике җиңүче ); укытучы - җиңүче һәм/яки соңгы 3 ел дәвамында Һөнәри осталык бәйгеләренең муниципаль яки республика этабында призер булырга тиеш.

Башлангыч сыйныф укытучысы буларак, дәгъва кылучының соңгы 4 ел дәвамында республика олимпиадаларының муниципаль этабында җиңүче һәм/яки

призер укучылары; соңгы 3 ел дәвамында ул Һөнәри осталык бәйгеләренең муниципаль яки республика этаплары җиңүчесе һәм призеры булырга тиеш.

“Укытучы-эксперт” номинациясендә грант ярдәме алуга дәгъва кылучы югары квалификация категориясенә ия булырга тиеш. Дәгъва кылучының соңгы 3 ел дәвамында республика һәм/яки бөтенроссия һәм/яки халыкара олимпиадаларда җиңүче һәм призер (җиңүче һәм/яки ике ел рәттән призер булган бер укучысы; яки бер ел эчендә кимендә ике җиңүче һәм/яки призерлары) укучылары булырга; укытучы республика дәрәҗәсендәге эксперт төркемнәренең (аттестация, дәүләт йомгаклау аттестациясе, фән олимпиадалары) әгъзасы булырга тиеш. Башлангыч сыйныф укытучысы буларак, дәгъва кылучының соңгы 4 ел эчендә республика олимпиадаларында җиңүче һәм призер булган укучылары, соңгы 4 ел эчендә республика дәрәҗәсендәге «Көнгерә», «Медвежонок» интеллектуаль конкурсларында җиңүче һәм призер укучылары булырга; соңгы 3 ел дәвамында укытучы аттестация буенча республика дәрәҗәсендәге эксперт төркеме әгъзасы булырга тиеш.

Соңгы өч елда бердәм дәүләт имтиханы (БДИ) нәтиҗәләре буенча канәгатьләнмәслек нәтиҗәләр, төп дәүләт имтиханы (ТДИ) нәтиҗәләре буенча төп гомуми белем турында (билгеләнгән фән буенча өлгермәү сәбәпле) аттестат алмаган укучылары булган укытучылар, шулай ук белем бирү сыйфатын милли тикшерүнең (алга таба – НИКО ) 2-4 сыйныфларда Бөтенроссия тикшерү эшләре (БТЭ) сыйфатын бәяләү системасы кысаларында бәяләү процедураларының канәгатьләнерлек булмаган нәтиҗәләре булган башлангыч сыйныф укытучылары грант ярдәмендә катнашуга кертелми.

Грант ярдәмен алырга теләүчеләр төп эш урыны буенча «Укытучы» вазыйфасы буенча гомуми белем бирү оешмасының штат хезмәткәре булырга тиеш.

1.3. Физик затлар керемена салым һәм Пенсия фондына, социаль иминият фондына, РФ Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондына иминият кертемнәрен исәпкә алмыйча, «Өлкән укытучы» номинациясендә - 4000 (дүрт мең) сум күләмендә, «Укытучы - мастер» номинациясендә - 5 000 (биш мең) сум күләмендә, «Укытучы - остаз» номинациясендә - 8 000 (сигез мең) сум күләмендә,

«Укытучы - эксперт» номинациясендә-10 000 (ун мең) сум күләмендә бүлеп бирелгән акчалар грант ярдәме була.

Грант ярдәменә бүлеп бирелгән акчалар 11 ай дәвамында грант алучыларга ай саен түләү өчен каралган.

Грант ярдәме «Өлкән укытучы» номинациясе буенча 280 грант алучыга, «Укытучы - мастер» номинациясе буенча 300 грант алучыга, «Укытучы - остаз» номинациясе буенча 150 грант алучыга, «Укытучы - эксперт»номинациясе буенча 108 грант алучыга бирелә.

1.4. Грант ярдәменә дәгъва кылучыларны конкурс сайлап алуы әлеге Положениедә билгеләнгән тәртиптә 2017 елның 7 февраленнән 28 февраленә кадәр ике этапта уздырыла. Беренче этапта документар конкурс сайлап алуы гамәлгә ашырылачак, аның нәтиҗәләре буенча икенче этап - әңгәмә уздырылачак. Сайлап алу Министрлык тарафыннан әлеге Положениенең 2 бүлеге нигезендә төзелә торган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру буенча Республика Эксперт комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.5. Грант ярдәме бирү турындагы карар, грант ярдәмен алу өчен конкурста һәм аны гамәлгә ашыру чорында, укытучы турында дөрес булмаган яки ялган мәгълүматларны ачыклаганда кабул ителми.

1.6. Грант алучы белән хезмәт мөнәсәбәтләре өзелсә, йә грант алучы бала өч яшькә җиткәнче карау өчен ялга чыккан очракта, Грант ярдәме күрсәтү турындагы карар гамәлдән чыгарыла, түләүләр туктатыла.

Грант алучы эшләгән белем бирү оешмасы Грант алучы белән хезмәт мөнәсәбәтләрен өзү яки Грант алучының, баланы өч яше тулганчы карау өчен ялга чыгуы турында 2 (ике) эш көне дәвамында элеге белем бирү оешмасы урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль районы мәгариф бүлегенә (алга таба - мәгариф бүлеге) хәбәр итәргә тиеш. Муниципаль район мәгариф бүлеге (идарәсе), үз чиратында, грант алучы белән хезмәт мөнәсәбәтләрен өзү, яки өч яшькә җиткәнчегә кадәр бала карау буенча грант алучының ялга чыгуы турында, эш көннәрендә

исәпләнгән 5 (биш) көн дәвамында, Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгына мәгълүмат бирергә тиеш

## 2. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәмен гамәлгә ашыру буенча республика Эксперт комиссиясе

2.1. Грант ярдәме күрсәтү өчен, укытучыларны сайлап алу максатыннан, Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәмен гамәлгә ашыру буенча 9 (тугыз) кешедән торган, составында комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатиб һәм комиссия әгъзалары булган республика Эксперт комиссиясе (алга таба - Республика эксперт комиссиясе) оештырыла.

2.2. Республика Эксперт комиссиясе түбәндәге хокукларга ия:

Республика олимпиада үзәгеннән, Татарстан Республикасы белем бирү сыйфатын мониторинглау республика үзәгеннән, мәгариф белән идарә итү муниципаль органнарыннан һәм Комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча башка оешмалардан материалларны һәм мәгълүматны соратып алырга;

кирәк булганда, конкурс материалларына өстәмә экспертиза үткәрү өчен, Республика олимпиада үзәгеннән, Татарстан Республикасы белем бирү сыйфатын мониторинглау республика үзәгеннән, мәгариф белән идарә итүнең муниципаль органнарыннан 1 әр белгечне җәлеп итәргә.

2.3. Республика Эксперт комиссиясе утырышларын Республика эксперт комиссиясе рәисе җитәкли, ә ул булмаганда - Республика эксперт комиссиясе рәисе урынбасары. Республика эксперт комиссиясе утырышлары, әгәр аларда комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокукый булып санала.

2.4. Республика эксперт комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

2.5. Республика эксперт комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигезләшкән очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

2.6. Республика эксперт комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия рәисе, ә ул булмаганда, комиссия рәисе урынбасары тарафыннан имзалана

3. Гант ярдәмен бирү өчен гаризалар бирү һәм конкурс үткәрү тәртибе

3.1. Грант ярдәме алуга Конкурс Министрлык боерыгы нигезендә үткәрелә.

3.2. Министрлык, 2017 елның 7 февраленнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында (http://mon.tatarstan.ru), «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме турында» боерык урнаштыру юлы белән, грант ярдәме бирүгә конкурс үткәрү турында хэбәр итә.

3.3. Грант ярдәме алуга конкурста катнашу өчен дәгъва кылучылар министрлыкка әлеге Положениенең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра һәм сайттагы мәҗбүри кырларны тутыра (http://uchiteltatarstan.ru): исеме, атасының исеме, фамилиясе, туган көне, җенесе, эш урыны, муниципаль районның исеме, гомуми педагогик стажы, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме, квалификация категориясе, бүләкләр, исемнәр.

3.4. Грант ярдәменә дәгъва итүчеләр - беренче категорияле укытучылар түбәндәге документларны тәкъдим итәләр:

беренче тапкыр яисә кабат алынган беренче квалификация категориясе булуны раслаучы документлар (боерыктан өземтә);

«Укытучы - мастер» номинациясендә - республика олимпиадаларының муниципаль этабында җиңүче укучылары булу турында яки соңгы 3 ел дәвамында үзенең Һөнәри осталык бәйгеләренең муниципаль яки республика этабында җиңүче булуын раслаучы документлар;

мотивацион хат:

«Өлкән укытучы» номинациясендә Татарстан Республикасы укытучысының һөнәри үсеш модельләренең биш компетенциясенә таянып, һөнәри дәрәҗәсен күтәргән очракта, дәгъва кылучыга әлеге эшкә кертә ала торган өлешен акцентлап, фән өлкәсе үсеше проблемаларын һәм перспективаларын чагылдырырга кирәк;

«Укытучы - мастер» номинациясендә Татарстан Республикасы укытучысының һөнәри үсеш модельләренең биш компетенциясенә таянып, Татарстан Республикасы мәктәпләрендә укучыларның үсеш проблемаларын һәм перспективаларын (укытыла торган фән өлкәсендә) күзаллауны һәм дәгъва кылучының әлеге эшкә кертә ала торган өлешен чагылдырырга кирәк;

"Өлкән укытучы" номинациясендә 2017 елда Грант алучының һөнәри үсешенә юнәлдерелгән проектының тасвирламасы;

"Укытучы-мастер" номинациясендә муниципаль районда 2017 елда тормышка ашырырга мөмкин булган проектның тасвирламасы (укытыла торган фән өлкәсендә);

дәгъва кылучы эшли торган гомуми белем бирү оешмасы директорының Татарстан Республикасы муниципаль районы мәгариф бүлеге башлыгы белән килешенгән бәяләмәсе (әлеге Положениегә 1,2 кушымталар).

Конкурста грант ярдәменә дәгъва итүчеләр-югары квалификацион категорияле укытучылар түбәндәге документларны тәкъдим итәләр:

"Укытучы остаз" номинациясендә- фән укытучылары өчен 5 документ, укучыларның 2-3 дипломы,соңгы 3 ел дәвамында республика олимпиадаларының муниципаль этабында җиңүче укучыларының булуын раслаучы укытучының 1-2 дипломы ( 1дән дә ким булмаган 2 ел рәттән җиңүче булган укучысы һәм/яки бер елда дәвамында 2 дән дә ким булмаган җиңүче укучылары) булуы турында;

Укытучының җиңүче булуы һәм/яки соңгы 3 ел дәвамында Һөнәри осталык бәйгеләренең муниципаль яки республика этабында призеры булуы турында;

башлангыч сыйныф укытучылары өчен 5 документ: укучыларның 2-3 дипломы, укытучының соңгы 4 ел дәвамында республика олимпиадаларының муниципаль этабында җиңүче укучыларының булуын раслаучы 1-2 дипломы,

соңгы 3 ел дәвамында үзенең Һөнәри осталык бәйгеләренең муниципаль яки республика этабында җиңүче укытучы һәм/ яки призёр булуын раслау турында;

мотивацион хат;

укытучысының һөнәри үсеш модельләренең биш компетенциясенә таянып, Татарстан Республикалары мәктәпләрендә остазлыкны һәм тьютор эшчәнлеген үстерү проблемалары һәм перспективалары турында һәм әлеге эшкә нинди өлеш кертергә мөмкин булуы турында тасвирларга;

Татарстан Респуьликасы  укытучыларының остазлык /тьютор эшчәнлеген үстерү планы;

Татарстан Республикасы  муниципаль районы мәгариф бүлеге (идарәсе) җитәкчесе бәяләмәсе (әлеге Положениегә 3 кушымта);

“Укытучы-эксперт” номинациясендә фән укытучылары өчен 4 тән артык булмаган документлар: укучыларның 2-3 дипломы, укытучының  соңгы  3 ел дәвамында укытучының республика һәм/яки Бөтенросия һәм/ яки халыкара олимпиадаларда җиңүче һәм/яки призёр  булган укучыларын раслаучы  1 дипломы ( 2 ел рәттән җиңүче һәм/яки призёр булган 1дән дә ким булмаган укучысы;  яки бер ел дәвамында 2 дән дә ким булмаган җиңүче һәм/яки призёр укучылары булуы турында; укытучының  соңгы 3 елда бер  республика дәрәҗәсендәге эксперт төркемнәре (аттестация, дәүләт йомгаклау аттестациясе, фән олимпиадалары) әгъзасы булуы турында; башлангыч мәктәп укытучылары өчен 4 тән дә артык булмаган документлар: укучыларның 2-3 дипломы, укытучының соңгы 4 елда республика олимпиадасы җиңүчесе һәм/яки призёры барлыгы турында 1 документы;соңгы 4 елда “Көнгерә”, “Медвежонок” республика дәрәҗәсендәге интеллектуаль конкурлар җиңүче  һәм/яки призёр укучылары булуы турында; соңгы 3 елда укытучының республика дәрәҗәсендәге Эксперт төркеме әгъзасы булуы турында.

Татарстан Республикасы  муниципаль районы мәгариф бүлеге (идарәсе) җитәкчесе бәяләмәсе (әлеге Положениегә 4 кушымта);

“Укытучы-эксперт “номинациясендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәгъва кылучының үз фәне өлкәсендә эксперт буларак эшенә бәяләмә (әлеге Положение 5 кушымта).

3.5 2017 елның 13 февраленнән дә соңга калмыйча, документлар электрон рәвештә рәсми сайтка (http/uchiteltatarstan.ru) җибәрелә. Документларны әлеге сроктан соң тапшырган очракта, дәгъва кылучыга конкурста катнашырга рөхсәт ителми.

3.6. Республика эксперт комиссиясе , 2017 елның 16 февраленә кадәр югары категорияле укытучылар өчен, 2017 елның 18 февраленә кадәр беренче категорияле укытучылар өчен, тапшырылган документларга алдан экспертиза үткәрә. Шулай ук вакытта Республика эксперт комиссиясенең ике әгъзасы тарафыннан документларның һәр пакетына карата әлеге Положениенең таләпләренә туры килүе турында язма эксперт йомгаклары (нәтиҗәләре) төзелә.

3.7. Тапшырылган материалларны анализлау нәтиҗәләре буенча, алга таба Республика эксперт комиссиясе тарафыннан төп сайлап алу этабында карап тикшерү өчен, документлары әлеге Положение таләпләренә туры килә торган дәгъва кылучылар сайлап алына, ул 2017 елның 20 февраленнән 21 февраленә кадәр югары категорияле укытучылар өчен, 2017 елның 22 февраленнән 24 февраленә кадәр - беренче категорияле укытучылар өчен комиссия рәисе раслаган график буенча уздырыла. График 2017 елның 18 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының мәгариф идарәсе органнарына электрон документлар әйләнеше системасында җибәрелә.

3.8. Республика эксперт комиссиясе шәхси әңгәмә рәвешендә, грант ярдәме алуга дәгъва кылучыларны сайлап алуның турыдан-туры этабын үткәрә. Грант ярдәме алучыларны сайлап алу өчен, рәсми сайтта http://uchiteltatarstan.ru Республика эксперт комиссиясенең һәр әгъзасына, системага керү өчен, логин һәм пароль бирелә. Әңгәмә вакытында комиссия укытучының профайлын һәм документларны тикшерү нәтиҗәләрен, шул исәптән тәкъдим ителгән материалларны анализлаганда ике эксперт ясаган кисәтүләрне карый. Әңгәмә барышында дәгъва кылучы 5 компетенция буенча бәяләнә: уңышлы лидер;

инновацион практикалар; актив граждан; компетентлы педагог; җаваплы остаз. Республика эксперт комиссиясе әгъзалары барлык биш компетенция буенча 0дән 5кә кадәр баллар куя. Нәтиҗәдә, һәр укытучы буенча барлык экспертларның бәяләрен исәпкә алып, уртача балл чыгарыла. Җыелган баллар рейтингыннан чыгып, җиңүчеләр барлык фәннәрне исәпкә алып, әлеге Положениенең п. 1.3. та күрсәтелгән күләмдә билгеләнә.

3.9. Конкурс нәтиҗәләре буенча республика эксперт комиссиясе тарафыннан 2017 елның 24 һәм 25 февраленә кадәр югары һәм беренче квалификация категориясе укытучылары өчен грант алучылар исемлеге төзелә һәм раслана. 3.10. Министрлык үзенең рәсми сайтында Югары һәм беренче квалификация категориясе укытучылары өчен 2017 елның 27 һәм 28 февраленә кадәр грант алучыларның расланган исемлеген урнаштыра.

## 4. Йомгаклау положениеләре

4.1. Грант ярдәмен финанслау Министрлыкның җыелма сметасында каралган акчалар хисабына тормышка ашырыла.

4.2. Грант ярдәме министрлыкның " 2017 елда Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме үткәрү йомгаклары турындагы” боерыгы нигезендә башка бюджетара трансфертлар рәвешендә муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә.

Субсидияләрне күчерү өчен нигез булып, Татарстан Республикасы министрлыгы һәм муниципаль берәмлеге арасындагы Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына грант ярдәме күрсәтү өчен башка бюджетара трансфертлар бирү хакындагы килешү тора.

4.3. Грант алучының белем бирү оешмасы белән хезмәт мөнәсәбәтләре өзелгән очракта, баланы өч яшькә җиткәнче карау өчен ялга чыкканда, грант ярдәме бирү турындагы карар гамәлдән чыгарыла һәм түләүләр туктатыла. Шул ук вакытта грант алучы эштән азат ителгәннән соң яки өч яше тулганчы бала карау буенча ялга чыккач, түләнгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджетына кайтарырга тиеш.

4.5. 2017 елның декабрендә грант алучылар министрлыкка мотивация хатында күрсәтелгән проект чараларын гамәлгә ашыру турында хисап тапшырырга тиеш. 2017 елда грант ярдәмен гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге турында йомгаклау хисабы, 2018 елның 20 февраленнән дә соңга калмыйча, министрлыкның рәсми сайтында(http://mon.tatarstan.ru) урнаштырыла.

4.6. Грант ярдәмен бирү кире кагылганда, укытучы тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Кушымта 1
Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме турында положениегә карата

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме күрсәтү буенча республика эксперт комиссиясе рәисенә

бәяләмә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «өлкән укытучы" грантын алуга конкурста катнашу өчен җибәрелә_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, квалификациясе (нинди елда бирелгән), вазифасы, эш урыны)

(*Татарстан Республикасы укытучысының һөнәри үсеш модельләренең биш компетенциясенә таянып, грант алырга теләүчеләрне тасвирлагыз һәм ни өчен нәкъ менә ул(алар) үзенең һөнәри үсешен тормышка ашыру өчен «Өлкән укытучы» грантын алырга тиеш икәнлеген аңлатыгыз*).

Соңгы өч елда Грант алырга теләүчеләрнең БДИ нәтиҗәләре буенча канәгатьләнерлек булмаган һәм билгеләнгән фән буенча өлгермәү сәбәпле, төп гомуми белем турында аттестат алмаган укучылары булмавын раслыйм.

Директор (ОУ исеме) / /

МП

Бүлек (идарә итү) / Татарстан Республикасы
Мәгариф (муниципаль район исеме) / /

МП

Дата:

Кушымта 2
Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме турында положениегә карата

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме күрсәтү буенча республика эксперт комиссиясе рәисенә

бәяләмә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Укытучы-мастер" грантын алу өчен конкурста катнашуга җибәрелә____________________________________________
____________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, квалификациясе (нинди елда бирелгән), вазифасы, эш урыны)

| | |
|---|---|
| Уңышлы лидерның<br>ни дәрәҗәдә уңышлы укытучының үз мәктәбе/ муниципаль районы укучылары өчен белем бирү һәм тәрбия чараларын үткәрү инициативасы белән чыкты? Зинһар, тәфсилләп языгыз | |
| Иннавацион практик<br>Укытучының үз мәктәбе/муниципаль районы укучылары өчен укытыла торган стандарт булмаган чаралар үткәрү тәҗрибәсе (чараларны үткәрүнең инновацион формалары һәм ысуллары һәм / яки чараларның инновацион эчтәлеге) бармы? Зинһар, тәфсилләп языгыз. | |
| Актив гражданин<br>укытучы рухи әхлакый кыйммәтләрне никадәр уңышлы үстерә һәм<br>укучыларга патриотик тәрбия бирү? Зинһар, тәфсилләп языгыз. | |
| Компетентлы педагог<br>үзенең мәктәп укучыларына үз фәннәрен ни дәрәҗәдә уңышлы укыта? Зинһар, тәфсилләп языгыз. | |

| | |
|---|---|
| җаваплы остаз укытучының укучылар һәм/яки үз мәктәпләре укытучылары өчен остаз сыйфатында башкарган эшчәнлеге ни дәрәҗәдә уңышлы? Зинһар, тәфсилләп языгыз.бу деталя | |

Кушымта 3
Татарстан Республикасы гомуми белем
бирү оешмалары укытучыларының һөнәри
үсешенә грант ярдәме турында
положениегә карата

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү
оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә
грант ярдәме күрсәтү буенча республика
эксперт комиссиясе рәисенә

бәяләмә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Укытучы-остаз» грантын алуга конкурста катнашу өчен җибәрелә ___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, квалификациясе (нинди елда бирелгән), вазифасы, эш урыны)

| | |
|---|---|
| Уңышлы лидер<br>укытучы остазлык эшчәнлеген оештыруда инициативаны күрсәтәме? Зинһар, тәфсилләп языгыз. | |
| Инновацион практик<br>укытучының остазлыкның инновацион программаларын эшләү тәҗрибәсе бармы? Зинһар, тәфсилләп языгыз Зинһар, тәфсилләп языгыз | |
| Актив гражданин<br>укытучыда рухи-әхлакый кыйммәтләрне укытуда үстерүгә юнәлдерелгән остазлык программаларында оештыру (яки катнашу) тәҗрибәсе бармы<br>һәм патриотик тәрбия? Зинһар, тәфсилләп языгыз | |
| Компетентлы педагог Россия Федерациясенең белем бирү стандартлары һәм иң яхшы халыкара практикаларга гамәлгә ашырылган остазлык программаларына туры киләме? Зинһар, тәфсилләп языгыз. | |

| | |
|---|---|
| Җаваплы остаз мәктәп/ муниципаль/ республика дәрәҗәсендә укытучыларның һөнәри үсешенә кандидат ярдәм итәме? Зинһар, тәфсилләп языгыз. | |

Грант алырга теләүченең БДИ нәтиҗәләре буенча канәгатьләнерлек булмаган һәм төп гомуми белем турында төп гомуми белем алу аттестаты алмаган, 2-4 сыйныфларда Бөтенроссия тикшерү эшләре сыйфатын бәяләүнең республика системасы кысаларында бәяләү процедураларының канәгатьләнерлек булмаган нәтиҗәләре булган, соңгы өч елда мәгариф сыйфаты буенча илкүләм тикшеренү нәтиҗәләре булмаган укучылары юк дип раслыйм.

Бүлек (идарә итү) / Татарстан Республикасы
Мәгариф (муниципаль район исеме) / /

МП

Дата:

Кушымта 4
Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме турында положениегә карата

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме күрсәтү буенча республика эксперт комиссиясе рәисенә

бәяләмә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы грантын алуга конкурста катнашу өчен «Укытучы-эксперт» җибәрелә_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, квалификациясе (нинди елда бирелгән), вазифасы, эш урыны)

| | |
|---|---|
| Уңышлы лидер<br>Укытучы үзенең фән өлкәсендәге тикшеренү проектлары белән элек ни дәрәҗәдә уңышлы җитәкчелек иткән? Зинһар, бу проектларны атагыз. | |
| Инновацион практик<br>Укытучының фән өлкәсендә укытуның инновацион алымнарын эшләү тәҗрибәсе бармы? Зинһар, тәфсилләп языгыз | |
| Актив гражданин<br>Укытучының рухи-әхлакый кыйммәтләрне үстерү элементларын кертү һәм үз фәннәрен укытуга патриотик тәрбия бирү тәҗрибәсе бармы? Зинһар, тәфсилләп языгыз. | |
| Компетентлы педагог<br>үзенең фән өлкәсендә укытуда һәм укытуда эксперт булып торамы? Зинһар, тәфсилләп языгыз.<br>. | |

| | |
|---|---|
| Җаваплы остаз<br>Татарстан Республикасының<br>башка укытучылары өчен<br>укытучы сыйфатында<br>укытучының эш нәтиҗәләре<br>нинди?  Зинһар, тәфсилләп<br>языгыз. | |

Грант алырга теләүченең БДИ нәтиҗәләре буенча канәгатьләнерлек булмаган һәм төп гомуми белем турында төп гомуми белем алу аттестаты алмаган, 2-4 сыйныфларда Бөтенроссия тикшерү эшләре сыйфатын бәяләүнең республика системасы кысаларында бәяләү процедураларының канәгатьләнерлек булмаган нәтиҗәләре булган, соңгы өч елда мәгариф сыйфаты буенча илкүләм тикшеренү нәтиҗәләре булмаган укучылары юк дип раслыйм.

Бүлек (идарә итү) / Татарстан Республикасы
Мәгариф (муниципаль район исеме) / /

МП

Дата:

Кушымта 5
Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме турында положениегә карата

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме күрсәтү буенча республика эксперт комиссиясе рәисенә

бәяләмә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Укытучы-эксперт " грантына дәгъва кылучыга»_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, квалификациясе (нинди елда бирелгән), вазифасы, эш урыны)

(Алга таба кандидатның үз фән өлкәсендә эксперт буларак грант алуга нәтиҗәлелеге, аның эксперт эшчәнлеген үстерү перспективалары, стратегик планлаштыру күнекмәләре булу, ирешелгән нәтиҗәләр һәм үсеш зоналары тасвирлана)

Вазифа / МП /

Дата:

*(Искәрмә:, әгәр дәгъва кылучы республика дәрәҗәсендәге йомгаклау аттестациясе, предмет олимпиадалары эксперт төркеме әгъзасы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Кадрлар сәясәте бүлеге башлыгы, республика дәрәҗәсендәге аттестация буенча эксперт төркеме әгъзасы булса, бәяләмәгә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү идарәсе башлыгы кул куя)*